КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 1 август г.Казань № 926

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирүче белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнар кабул итүнең контрольдә тотыла торган саннарын бүлүгә конкурс үткәрү комиссиясе турында» 2015 ел, 15 гыйнвар, 6 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт аккредитациясе булган белем бирү оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәр белеме һәм югары белем бирүче белем бирү программалары буенча укыту өчен һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча гражданнар кабул итүнең контрольдә тотыла торган саннарын бүлүгә конкурс үткәрү комиссиясе турында» 2015 ел, 15 гыйнвар, 6 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 10 апрель, 235 нче; 2016 ел, 13 май, 302 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 972 нче; 2017 ел, 4 октябрь, 757 нче; 2018 ел, 9 апрель, 217 нче; 2019 ел, 6 сентябрь, 788 нче, 2020 ел, 17 сентябрь, 842 нче, 2021 ел, 20 август, 752 нче, 2022 ел, 13 август, 812 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба - Комиссия) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларының урта һөнәри һәм югары белемнең уку-укыту программалары буенча белем бирү өчен әзерлек һөнәрләре, белгечлекләре һәм юнәлешләре буенча гражданнарны кабул итүнең контроль саннарын Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бүлүгә дәүләт аккредитациясе булган мәгариф оешмалары арасында конкурс үткәрү комиссиясе турында нигезләмәнең 1.5 пунктының беренче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларының урта һөнәри һәм югары белемнең уку-укыту программалары буенча белем бирү өчен әзерлек һөнәрләре, белгечлекләре һәм юнәлешләре буенча гражданнарны кабул итүнең контроль саннарын Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән бүлүгә дәүләт аккредитациясе булган мәгариф оешмалары арасында конкурс үткәрү комиссиясе составында:

Комиссия составыннан Н.Р.Залаковны, А.Н.Җәләловаңы, Э.А.Зариповаңы, Н.В.Кондратованы, Т.В.Никоновны, О.В.Страхованы чыгарырга;

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Тонконог Софья Львовнаны | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының һөнәри укыту һәм һөнәри юнәлеш бирү бүлеге башлыгын, Комиссия секретарен |
| Гарипов Ленар Наил улын | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасарын |
| Захарян Артур Аршамовичны | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Стратегик үстерү идарәсе башлыгын |
| Миңнуллин Юлай Рим улын | Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасарын |
| Фатыйхов Илдар Рәзин улын | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасарын; |

Таҗетдинова Клара Алексеевна вазыйфасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасарын, Комиссия рәисен».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин